СОВЕТ
АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

15.12.2025 г. Агрыз № 4-4

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 2022елның 5 сентябрендә кабул ителгән 19-1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы депутаты статусы турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Норматив хокукый актны гамәлдәге законнарга туры китерү максатында, Татарстан Республикасы Конституциясенә таянып, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1.Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 2022елның 5 сентябрендә кабул ителгән 19-1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Әгерҗе муниципаль районы депутаты статусы турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 нче маддәнең 3 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«Татарстан Республикасы Башлыгыннан (Рәистән) депутат вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында гариза белән мөрәҗәгать иткән очракта, вәкаләтләрне вакытыннан алда туктату өчен нигез барлыкка килгән көн булып, Татарстан Республикасының Әгерҗе муниципаль районы Советына әлеге гариза килеп кергән көн санала»;

1.2. 18 нче маддәнең 1 нче пунктының "б" бүлекчәсен түбәндәге редакциядә язарга:
«коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә бушлай катнашу (сәяси партияне, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында төзелгән башлангыч профсоюз оешмасының сайланган органы, муниципаль берәмлек сайлау комиссиясенең аппараты идарәсендә катнашудан, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, милекчеләр берләшмәсенең съездында (конференциясендә) яки гомуми җыелышында катнашудан тыш) Татарстан Республикасы Башлыгына (Рәисенә) алдан хәбәр итү юлы белән, Татарстан Республикасы законында билгеләнгән тәртиптә».

2. Бу карарны Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга, шулай ук Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) интернет челтәрендә бастырып чыгарырга.

3. Бу карарның үтәлешен контрольгә алуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының законлылык, регламент һәм депутат әхлагы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет Рәисе,
Муниципаль район Башлыгы Л.Ф. Нургаянов